Техникумда «Түбәтәйне яса һәм бизә» дигән иҗади бәйге үткәрелде. Конкурс студентларда Татарстан тарихына һәм мәдәниятенә карата кызыксыну уяту, туган якка, милли гореф-гадәтләргә мәхәббәт һәм хөрмәт тәрбияләү, укучыларны иҗади эшчәнлеккә кызыксындыру, аларның иҗади сәләтләрен үстерү максатыннан үткәрелде. Тәкъдим ителгән түбәтәйләр арасында иң яхшылары сайлап алынды. Шамбазова Камилла (404 төркем студенты), Сагдеева Алинә (404 төркем студенты), Ассадуллина Илнара (129 төркем студенты) җиңүче булды. Барлык катнашучылар да дипломнар белән бүләкләнде.













